РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
Агерзинского сельского поселения
Азнакаевского муниципального
района

ул. Г. Ахметова, д. 14а, село Агерзе,
Азнакаевского муниципального
района, 423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге Советы
**БАШЛЫГЫ**

Г. Әхмәтова урамы, 14а,
Әгерҗе авылы
Азнакай муниципаль районы,
423303
Тел. (факс) 8(8-5592) 44-5-21
E-mail: Ager.Azn@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» октябрь 2023 ел №4

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлегендә Мәнәвез торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Уставы нигезендә, карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Әгерҗе авыл җирлегенең Мәнәвез торак пунктында теркәлгән Үзәк урамы 1 йорттан 75 йортка кадәр сайлау хокукына ия булган гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2023 елның 18 октябрендә 9 сәгать 00 минутка беренче этабын билгеләргә. Үткәрү урыны: Мәнәвез торак пункты, Совет урамы, 1а.
2. Билгеләргә:
   - Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлегендә Мәнәвез торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын оештыручы итеп, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлегенең Башкарма комитетын;
   гражданнар җыенынын үткәрү вакыты - 2023 елның 18 октябрендә 9.00 сәгатьтән 10.00 сәгатькә кадәр.

   3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авыл җирлеге Башкарма комитетына түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:
   - 2023 елның 11 октябреннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Әгерҗе авылы Башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышуны Әгерҗе авылы Г. Әхмәтова урамы 14а, Мәнәвез торак пункты, Совет урамы 1а адреслары буенча тәэмин итәргә.
   - сайлау хокукына ия булган Үзәк урам буенча Мәнәвез торак пунктында яшәүчеләрнең исемлеген төзергә;
   - гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- массакүләм мәгълүмат чараларында Мәнәвез торак пунктындагы Үзәк урамындагы халыкка гражданнар җыены турында хәбәр итәргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне түбәндәгечә расларга:

"Сез 2024 елда Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Мәнәвез торак пункт территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә ризамы, түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтелгән:

- җир асты суларының (чишмәләрне) табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (Мәнәвез торак пунктындагы «Расиха» чишмәсен төзекләндерү).

«РИЗА» «КАРШЫ»

7. Әлеге карарны түбәндәге чаралар ярдәмендә халыкка игълан итәргә:

- Татарстан Республикасы, Азнакай муниципаль районы, Әгерҗе авыл җирлеге, Мәнәвез торак пунктындагы Совет урамы, 1а, 60 йортка каршы урнашкан Үзәк урамындагы мәгълүмати стендларда урнаштырырга;

- Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru урнаштырырга.

- Әлеге карарны, кабул ителгән көннән алып 10 көн эчендә, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча». http://aznakaevo.tatarstan.ru бастырырга.

Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.

Азнакай муниципаль районы
Әгерҗе авыл җирлеге
Башлыгы Н.Н.Хәсәнов